# *Газиз Салихҗан улы КАШАПОВ*

Татар халкы һәм әдәбияты көтмәгәндә зур югалту кичерде. Озакка сузылган каты авырулардан соң, 30 август көнне иртән татар совет язучысы ГАЗИЗ САЛИХҖАН улы КАШАПОВ (Газиз Кашшаф Үзиле) вафат булды.

Газиз Кашапов 1942 елның 21 августында Татарстанның Аксубай районы Яңа Үзиле авылында туган. Кечкенәдән әти-әнисез калган Газиз әбисе тәрбиясендә үсә. 1957 елда ул туган авылының җидееллык, 1960 елда Иске Ибрай авылы урта мәктәбен тәмамлый. Ул колхозда бухгалтер ярдәмчесе, аннары тракторчы һәм клуб мөдире булып эшли. 1962 елның көзендә Совет Армиясенә алынып, башта курсант, соңыннан гаскәри частьта механик булып хезмәт итә, хәрби училище тәмамлый. 1971 елның февраленә кадәр хәрби хезмәттә. 1969 елда хезмәт вазифаларын үтәгән чакта алган җәрәхәтләрдән каты авырып китеп, бик озак госпитальдә дәвалана һәм ахырда хәрби эштән китәргә мәҗбүр була.

1973 елда Г.С.Кашапов Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керә, бер үк вакытта 1974-1978 еллар арасында Татарстан китап нәшриятында кадрлар бүлеге инспекторы, Әлмәт шәһәрендә чыга торган "Хезмәт байрагы" газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли.

1978 елда Г.С.Кашапов Чаллы каласына күчеп килә. Ул әүвәл КамАЗ радиотапшырулар редакциясендә корреспондент, аннары "Социалистик Татарстан" газетасының Түбән Кама, Алабуга, Мамадыш, Тукай районнарындагы үз хәбәрчесе һәм язучыларның Чаллы оешмасында пропаганда бүлеге хезмәткәре. 1983 елда ул СССР Язучылар Союзына кабул ителде, 1988-1989 елларда Чаллы Язучылар оешмасының җаваплы секретаре булып торды.

Г.С.Кашаповның беренче әдәби әсәрләре 1970 еллар башында республика матбугатында дөнья күрә башлады. 1978 елда Татарстан китап нәшриятында аның "Сәмум җиле" дип исемләнгән тәүге китабы басылып чыкты. Шуннан соң "Еллар тыныч иде", "Язмышыңа ышан", "Гомернең утлы өлеше", "Вөҗдан хәтере" дигән китаплары бер-бер артлы дөнья күрде. Ул әдәбият сөючеләр арасында талантлы прозаик буларак танылды. Соңгы елларда ул халкыбызның сөекле шагыйре Хәсән Туфан турындагы тарихи романның беренче китабын тәмамлады. "Тилчә тамыры" дигән повестын машинкадан чыгарып бетереп килә иде.

Г.С.Кашапов безнең арабыздан үзенең иҗаты ныклап чәчәк аткан чорда китеп барды. Аның якты исеме һәм матур әсәрләре безнең күңелләрдә мәңге сакланыр.

**Халык депутатларының шәһәр Советы Президиумы, шәһәр Советы башкарма комитеты, Чаллы Язучылар оешмасы, Татар иҗтимагый үзәге идарәсе, "Милли йорт" җәмгыяте шурасы, Крайны өйрәнү җәмгыятенең региональ идарәсе, "Аргамак" журналы, "Нур", "Чулман-Идел", "Якты юл", "Таң йолдызы", "Челнинская газета", "Время" газеталары редакцияләре.**